ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-02-22, факс (85552) 3-13-44, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
15.07.2019

КАРАР
ПР-145

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 13 ноябрендәге ПР-194 номерлы «Авыл җирлегендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында " карарына үзгәрешләр кертү турында.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел 13 март, 181 нче «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турындагы " карары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Авыл җирендә, Эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 ел, 13 ноябрь, ПР-194 нче "Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турындагы " карарын түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункты белән тулыландырырга:

«11.1. Субсидия-ташламалар бирү гражданда закон көченә кергән суд акты белән расланган торак урыннарына һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча соңгы өч елдан да артмаган бурычлар булганда туктатыла.

Субсидия-ташламалар бирүне яңарту турында карар кабул иткәндә ул шулай ук субсидия-ташламалар бирү туктатылган айлар өчен дә түләнә.

2. Әлеге Карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет Җитәкчесе И. Ш. Бариев